СОВЕТ АКСУБАЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

23.09.2021 п.г.т. Аксубаево № 81

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы җирле үзидарә депутатына, сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яисә тулы булмаган мәгълүматлар биргән өчен, әгәр дә бу мәгълүматларны бозу җитди булмаса, җаваплылык чараларын куллану турында карар кабул итү Тәртибе хакында» 2020 елның 4 июнендәге 255 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә һәм Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы прокуратурасының 2021 елның 24 августындагы 02-08-02 номерлы протестына бәйле рәвештә, Аксубай муниципаль районы Уставына таянып, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы җирле үзидарә депутатына, сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яисә тулы булмаган мәгълүматлар биргән өчен, әгәр дә бу мәгълүматларны бозу җитди булмаса, җаваплылык чараларын куллану турында карар кабул итү Тәртибе хакында» 2020 елның 4 июнендәге 255 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Кушымтаның 2 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«2. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 40 статьясындагы 7.3-1 өлеше нигезендә муниципаль

вазыйфаларны биләүче затларга, аерым алганда, авыл җирлекләре депутатларына, район Советы депутатларына, район башлыгы, район башлыгы урынбасарына, авыл җирлекләре башлыкларына, контроль-хисап палатасы Рәисенә керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес яки тулы булмаган мәгълүмат тапшыручыларга, әгәр дә бу мәгълүматларны бозу җитди булмаса, түбәндәге җаваплылык чаралары кулланылырга мөмкин: 1) кисәтмә;

2) Аксубай муниципаль районы җирле үзидарә сайланулы органы әгъзасы депутатны, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Советында, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы җирле үзидарә сайланулы органында вазыйфадан азат итү Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Советында, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы җирле үзидарә сайлау органында аның вәкаләтләре срогы тәмамланганчы, вазыйфа биләүдән мәхрүм итү;

3) вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашырудан азат итү, аның вәкаләтләре срогы тәмамланганчы, даими нигездә гамәлгә ашыру хокукыннан мәхрүм итү.

4) Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Советында, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы җирле үзидарә сайланулы органында, аның вәкаләтләре срогы тәмамланганчы, вазыйфаларны биләүне тыю;

5) вәкаләтләр срогы тәмамланганчы, даими нигездә вәкаләтләрне үтәүне тыю»

2. Әлеге карарны Аксубай муниципаль районының http://aksubayevo.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштырырга һәм http://pravo.tatarstan.ru хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Аксубай муниципаль районы Советының Җирле үзидарә, законлылык, хокук тәртибе, регламент һәм депутат этикасы буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Аксубай муниципаль районы башлыгы,

Совет Рәисе

К. К. Гыйлманов